| Республика Татарстан<br>Менделеевский муниципальный<br>район Совет<br>Татарско-Челнинского сельского<br>поселения | Татарстан Республикасы<br>Менделевск муниципаль районы<br>Татар -Чаллысы авыл җирлеге<br>Советы |
|---|---|

**Р Е Ш Е Н И Е** **К АРАР**

2020 елның 28 маеннан №170

Менделеевск муниципаль районы
Татар Чаллысы авыл җирлегенең
2016 елның 23 мартындагы
27 номерлы карарына
үзгәрешләр кертү турында

Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексының 18 статьясы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Татар Чаллысы авыл җирлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Татар Чаллысы авыл җирлеге Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Татар Чаллысы авыл җирлеге Советының 2016 елның 23 мартындагы 27 номерлы карары “Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Татар Чаллысы авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру, шулай ук Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Татар Чаллысы авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакында нигезләмә” белән расланган Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Татар Чаллысы авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру, шулай ук Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Татар Чаллысы авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакында Нигезләмәгә киләсе үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 5 пунктын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә
«5. Тиешле исемлеккә кертелгән муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче муниципаль хезмәткәр үзенең чыгымнары турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру өчен билгеләнгән тәртиптә һәм форма буенча белешмәләр тапшырырга тиеш.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында http://mendeleevsk.tatarstan.ru «Татар Чаллысы авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татар Чаллысы авыл җирлеге
Советы Рәисе Т.П.Кузнецова.